| | | |
|---|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.07.2024 Казан ш. №01-05/191-пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 14 февралендәге 01-05/60-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 14 февралендәге 01-05/60-пр номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 01.03.2022 ел, №01-05/68-пр, 05.10.2022 ел, №01-05/225-пр, 01.03.2023 ел, №01-05/61-пр, 25.08.2023 ел, №01-05/170-пр, 30.01.2024 ел, №01-05/21-пр, 26.03.2024 ел, №01-05/85-пр боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәдә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссиянең төп бурычы – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенә түбәндәгеләрдә ярдәм итү:

а) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне

һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында алар тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычлар үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә (алга таба – Идарә) коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыру.»;

15 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

16.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.4. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерүләр Идарәдә коррупциягә каршы тору өчен җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли.»;

16.5 пунктында «15 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «15 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

16.6 пунктта:

«а» пунктчасында «15 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «15 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча дәлилле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 23, 24.3, 25.1, 25.2 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.»;

17.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

18 пунктта «15 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

18.1 пунктның «а» пунктчасында «15 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, моңа нигезләр булган очракта, комиссия әлеге Нигезләмәнең 21-24.3, 25.1-25.2 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

түбәндәге эчтәлекле 25.2 пунктын өстәргә:

«25.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составында:

комиссия составыннан чыгарырга:

А.В.Лохотскийны, Р.Н.Хафизовны;

комиссия составына кертергә:

Медведев Владимир Михайловичны – Механизация һәм техник сервис институты директорын, т.ф.к., «Казан дәүләт аграр университеты» югары һөнәри белем бирү ФДБМУ «Машиналарны эксплуатацияләү һәм ремонтлау» кафедрасы доценты (килешү буенча);

Корнилов Юрий Владимировичны – Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең коррупциягә каршы мониторинг бүлегенең баш киңәшчесен (килешү буенча).

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Р.Р.Кадыйров